Аллаһыдан курыксагыз, балаларыгыз арасында гадел хөкемле булыгыз
Хәдис

№11 (219)
5 февраль
1998 ел

Көмеш кыңгырау

Әти-әниләргә
Ярдәмче
Махсус чыгарылыш

Чаллы шәһәре ❀ Балалар һәм яшүсмерләр газетасы

Иң, иң, иң... конкурсы

Гади генә оста

Әзһәр абый Гәрәев быел 60 яшен тутырып лаеклы ялга чыгарга җыена. Мин аңа ныклы сәламәтлек, озын гомер, бәхетле картлык телим.

Әзһәр абый 16 яшеннән үк механизатор булып колхозда эшли башлаган. Җәй, көз көннәрендә комбайнда, ә яз, кыш көннәрендә тракторын җигәрләгән. Таң атканнан алып төн уртасына кадәр алны-ялны белмичә иген иккән, басу җирләрен эшкәрткән. Ә аның тормыш иптәше Мәүлидә апа комбайн-трактор гөрелтесе тавышын тыңлап, тәмле-тәмле ризыкларын пешереп, Әзһәр абыйны эштән көткән.

Әзһәр абый үзенең 3 улын да кешелекле, хезмәт сөючән итеп тәрбияләгән. Әзһәр абыйның улларына колхоз басуының һәр квадрат метры таныш. Ул аларның һәммәсен дә 5 класстан комбайнчы ярдәмчесе итеп үзе белән йөрткән. Кечкенәсе ярдәмче булса, зурысы әтисенең тракторы белән җир эшкәрткән.

Әзһәр абый гел алдынгылар сафында барган. Аның алган бүләкләре санап бетергесез! Аңа 9 Мактау грамотасы, 3 Почет дипломы, III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены, 1973-1979 елларның "Социалистик ярыш алдынгысы" билгеләре, "В.И.Ленинның 100 еллыгын каршылап" медале бирелгән. Бик күп кыйммәтле бүләкләр дә алган ул. Безнең Әзһәр абый - Татарстан республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы.

Әзһәр абый сәламәтлеге какшау сәбәпле, үзенең тракторын улы Фәннүргә тапшырды да, хәзерге көндә алачыкта тимерче булып эшли. Ул барлык техниканы язгы чәчүгә, уңышны җыеп алуга ярдәм итә.

Яшь механизаторларга үзенең киңәшләрен бирә. Тимерче бүтән төрле эшләрне дә оста итеп эшли белергә тиеш бит әле. Әзһәр абый нәкъ менә шундый кеше дә инде. Кайсыдыр бабайның арбасы яисә чанасы ватыла, кайсыбер әбинең самоварыннан су китә, чәйнек тоткасы төшә, йә булмаса табагачы сына. Боларның барысын да оста куллы Әзһәр абый төзәтә. Вакытым юк диеп, берсен дә борып җибәрми. Шуңа күрә дә инде аның турында авыл кешеләре: "Безнең Әзһәрнең куллары алтын", - диеп сөйлиләр. Менә шундый инде безнең Әзһәр абый!

Гөлнара ШӘМСЕМӨХӘММӘТОВА,
Минзәлә районы, Усай мәктәбе, 6"А" сыйныф.
Автор рәсеме.



Нур сибүче бер дә җиңел түгел

Минем әнием укытучы. Шуңа күрә мин бу хезмәт белән шөгыльләнгән кешене тәүлек буе күзәтә алам. Өйдә - әниемне, мәктәптә- укытучыларымны. Иртәнге караңгыдан торып эш киемнәрен киеп авыл укытучысы мал карарга чыгып китә. Җәй буе мал ризыгы әзерли, колхозга булыша. Димәк, ул терлекче, игенче хезмәтеннән дә читтә калмый. Аннан матур, чиста итеп киенеп, балаларга үрнәк булырдай тыйнак адымнар белән мәктәпкә китә. Күңелендә нинди генә тойгылар булса да, синең белән елмаеп исәнләшә, күңел биреп, онытылып дәрес аңлата. Ә бит шушы 45 минут дәресне бирер өчен, әле ул өйдә күпме хезмәт куеп дәрескә әзерләнә. Димәк, әле ул өйдә дә укый, белемен арттыра, гомере буе укый. Төзүчене дә, колхозчыны да, врачны да, артистны да укытучы укыта. Менә монда инде чынлап та иң, иң, иң кирәкле, иң мактаулы.... (әле бу санауны тагын да дәвам итеп булыр иде) дияргә була. Бу хезмәт кешеләренә хөрмәтем һәм соклануым минем бервакытта да кимемәс.

Укытучым - таянычым,
Укытучым - маягым,
Укытучым бу тормышка
Нур сибүче кояшым.

Назлыгөл ШӘКҮРОВА, Тукай районы, Тл. Тамак мәктәп-гимназиясе, 8 сыйныф.

Мөҗәһит

Яшәр туган телебез

Безнең бабайлар сүзләрне
Каян эзләп тапканнар,
Әллә инде ераклардан
Сатып алып кайтканнар.

Югыйсә бит алар әле
Галим дә булмаганнар.
Ә сүзләрне, исемнәрне
Барыбер уйлаганнар.

"Җир"не "Җир" дип,
Ә Кояшны "Кояш" дип атаганнар.
Айга да бит "йолдыз" диеп
Атама такмаганнар.

Кайвакыт исем сайлауның
Ансат юлын тапканнар.
Берәр хәрефне кушканнар
Яки алып атканнар.

Шуннан "сабый" "абый" булган,
"Әни"дән "нәни" туган.
"Тәти"не кыскарткач "әти",
Ә "бәби" "әби" булган.

Күрше урыс теле белән
Исемнәр алышканбыз.
Алар - безгә, без аларга
Кунакка барышканбыз.

Шуннан "кровать" "карават",
"Смола" булган "сумала".
Дуслык шулай сүзләр биреп,
Сүзләр алып сынала.

Шул сүзләрне, исемнәрне
Югалтмыйча сакласак,
Бабайларның васыятен,
Ышанычын акласак,

Безгә дә оныкларыбыз
Рәхмәт укыр, белегез.
Үзебездән генә тора,
Яшәр туган телебез.

Сөенечле хәбәр

Хәдичәләр, Нәриманнар кайта

Балага исем сайлаганда әти-әнигә бик нык уйланырга кирәк. Исемнең җисемгә туры килүе бик мөһим, чөнки язмышка йогынты ясавы да бик мөһим. Бала үз исеме белән горурланып яшәрдәй булсын.

Үткән ел Чаллыда 5 мең бала туды. Рус милләтеннән булган балаларга күбрәк Александр, Андрей, Сергей, Николай, Михаил, Анна, Алена, Наталья исемнәрен биргәннәр.

Татар балаларына иң күбе Айдар, Айрат, Дамир, Илнур, Ленар, Марат, Алина, Гөлнара, Лилия, Ләйсән, Миләүшә дип исем кушканнар. Кайбер нәниләргә Хәдичә, Җәүдәт, Нәриман, Тимербулат дигән бик борынгы, әмма искиткеч матур исемнәр дә куелган. 21нче гасырда аларга да һичшиксез:

"Исемең матур, кемнәр куйган?
Сине күреп кем туйган", - дип җырлаячаклар.

Әти-әниләр игътибарына!

Машинагыз бармы?

Юл-транспорт һәлакәтләрен киметү, халыкка хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту максатында һәм ДАИның автомобильләргә диагноз кую станциясе файдаланылуга тапшырылу нәтиҗәсендә быел машиналарны техник караутикшерү диагностика станциясендә үткәреләчәк. Бу түбәндәге машиналарга кагыла: пассажирлар йөртү өчен кулланыла торган транспорт чаралары, куркыныч йөк ташучы автомобильләр, коммерция структураларының транспортлары, чит илдә эшләнгән автомобильләр һәм 5 елдан артык файдалануда булган җиңел автомобильләр.

Башка төр транспортның техник торышын тикшерү "РОВИАТ" техник-хезмәт күрсәтү станциясе районында 1998 елның 1 апрелендә башланачак. 1994, 1995, 1996, 1997, 1998 елларда чыгарылган транспорт чараларының техник торышы тикшереләчәк.

Түбәндәге документларның булуы мәҗбүри:

1. Медицина белешмәсе.

2. Яңа үрнәктәге медицина аптечкасы.

3. Техник торышы тикшереләчәк транспорт чарасының яңа үрнәктәге "токсичность" талоны.

4. Техник карау өчен түләгән квитанция (УГАИ МВД РТ р/с 405038 10262230100002 Банк "Татарстан" СБ РФ г. Казань).

5. Транспорт чарасы хуҗасының соңгы 2 елда налог түләвен раслаучы квитанция.

6. Шәхси паспорт (хуҗаның).

7. Машинаның техник паспорты һәм йөртү хокукы бирә торган ышаныч кәгазе.

Барлык сораулар белән дә Комсомол Эчке эшләр бүлегенең ГАИ бүлегенә түбәндәге телефон белән мөрәҗәгать итәргә була: 42-64-84.

Каләм изгегә тартыр –

Хөрмәтле әти-әниләр һәм нәни дусларыбыз! Сезгә күңелебез түрендә инде бик күптән йөргән кечкенә бүләгебезне ирештерәбез. Бүгенге сәхифәбезне газета укучыларыбызның иң кечкенәләренә - мәктәп бусагасын быел тәүге кат атлап керергә җыенучы сабыйларга һәм әле яңа гына хәреф таный, язарга өйрәнеп килүче 1 сыйныф балаларына багышларга булдык. Киләчәктә сез дә актив хәбәрчеләребез булырсыз: әр-яңа шигырь, хикәя, әкиятләр язып безне дә сөендерерсез дип ышанабыз.

Гөлзада ӘХТӘМОВА

Хәрефләр өйрәнгәндә

"Әлифба" битләрендә
Хәрефләр сөйләшәләр,
Уйныйлар, сикерәләр
һәм дә йөгерешәләр.

Бер-бер артлы тезик тә,
Бер тәртип кертик әле,
Бераз күз йөртик әле:

Аа - иң алдан алдырган,
Ап-ак атка атланган.

Бб - бал, балык ярата,
Балаларга тарата.

Вв - вакытсыз уята,
Савыт-сабаны вата.

Гг - гади кадак кага
Бакчадагы таганга.

Дд - дөрес йөри атлап,
Дүрт түгел - ике аяклап.

Ее - елыша еландай,
Елый елак малайдай.

Жж - журналда выжылдый,
Мин божан, крыжовник, ди.

Зз - ул зәп-зәңгәр күздә,
Елмаеп карый безгә.

Ии - ишкәк ишә икән,
Иртәгә нишләр микән?

Йй - йөдәтә, йөгертә,
Йә йомгак тәгәрәтә.

Кк - кара карга күреп,
Карылдап китәр кебек.

Лл - лалә гөлләрендә,
Чәчәкләр илләрендә.

Мм - ул матур урманда,
Миләш, имән булганда.

Нн - сөя нәниләрне,
Нәрсә, нигә, ниләрне?

Оо - очкыч булып оча,
Болытны менеп коча.

Пп - песи-пескәемдә,
Ипинең пешкәнендә.

Рр - кап-кара каргада,
Бар ул ап-ак карда да.

Сс - Сара су сала, ди,
Сары сагыз сата, ди.

Тт - ошаган тырмага,
Әйтә: "Тизрәк тырмала!"

Уу - уйлап укыгыз, ди,
Урындыкка утырыгыз, ди.



Фф - файдалы мин ич, ди.
Дәфтәр, хәрефтә ич, ди.

Хх - хәрефле хат була,
Алып куйсаң, ат була.

Цц - цирк дигән сүздә,
Ансыз күңелсез безгә.

Чч - чебидә, чебендә,
Чәбәләнә кичен дә.

Шш - шалкан үстеме, ди.
Ашыгыз пештеме, ди.

Щщ - койрыклы рәвештә
Плащ, щетка, борщта.

Ъъ - ике эшне ярата,
Аера, калынайта.

Сабый күңелен яктыртыр

Ыы - ыргак кебек кәкре,
Ә шулай да бик дәртле.

Ээ - эттә һәм энемдә,
Бар кадагыч энәдә.

Ьь - төрле хезмәт итә,
Аера, йә нечкәртә.

Юю - юрган юа икән,
Юкагә менеп киткән.

Яя - язын яшьним мин, ди.
Ояда яшим мин, ди.

Әә - әни һәм әбидә,
Безнең нәни бәбидә.

Үү - күлдә үскән үрдәк,
Аңа үлән дә кирәк.

Өө - өенә йөгерә,
Кечкә кайтып өлгерә.

Җҗ - җиләк җыя җәен,
Беләм бик уңган җирен.

Ңң - койрык такканга,
Бигрәк уңайсыз аңа.

Һһ - бар һәрбер шәһәрдә,
Мәйдандагы һәйкәлдә.

Хәзерге татар алфавиты

Басма хәреф	Язма хәреф	Хәрефләрнең исемнәре	Басма хәреф	Язма хәреф	Хәрефләрнең исемнәре
А а	*А а*	а	У у	*У у*	у
Б б	*Б б*	бэ	Ф ф	*Ф ф*	эф
В в	*В в*	вэ	Х х	*Х х*	ха
Г г	*Г г*	гэ	Ц ц	*Ц ц*	цэ
Д д	*Д д*	дэ	Ч ч	*Ч ч*	че
Е е	*Е е*	е	Ш ш	*Ш ш*	ша
Ж ж	*Ж ж*	жэ	Щ щ	*Щ щ*	ща
З з	*З з*	зэ	ъ	*ъ*	АЕРУ һәм КАЛЫНЛЫК БИЛГЕСЕ
И и	*И и*	и	Ы ы	*Ы ы*	ы
Й й	*Й й*	кыска й	ь	*ь*	АЕРУ һәм НЕЧКӘЛЕК БИЛГЕСЕ
К к	*К к*	ка	Э э	*Э э*	э
Л л	*Л л*	эль	Ю ю	*Ю ю*	ю
М м	*М м*	эм	Я я	*Я я*	я
Н н	*Н н*	эн	Ә ә	*Ә ә*	ә
О о	*О о*	о	Ө ө	*Ө ө*	ө
П п	*П п*	пэ	Ү ү	*Ү ү*	ү
Р р	*Р р*	эр	Җ җ	*Җ җ*	җэ
С с	*С с*	эс	Ң ң	*Ң ң*	эң
Т т	*Т т*	тэ	Һ һ	*Һ һ*	һэ

Күл буенда шаулармын,
"Ш" белән мине язсаң,
Ат муенында булырмын,
"Т" белән алыштырсаң.

Ул урынга "Р" куйсаң,
Кисә аласың токмач.
"Л" белән - кырда калам
Игенне урып-җыйгач.

Таулар булып сузылыр,
"У" белән язсаң аны.
Диңгез булып җәелер,
Ул урынга куй "А"ны.

Биш хәрефтән торган сүзләр языгыз. Уртадагы хәрефе "Б" булсын. Сүзләрнең хәрефләре ике яктагы буш шакмакларга языла, сүзләр берлек санда, баш килештә булу шарт.



"Ял сәгатьләрендә" китабыннан алынды



Язма хәрефләр белән бирелгән бу алфавитны кисеп алып, каты катыргыга ябыштырыгыз да, калын полиэтилен белән тышлагыз. Каләмегезне хәрефләр өстенгә йөртеп, матур язарга өйрәнегез.

Кабат куллану өчен алфавитны бераз гына сабын кушылган жылы су белән сөртеп алу да җитә һәм сез күп тапкырлар язып карый-карый язарга остарып бетәрсез.

Ислам динендә "Йолдызнамә"нең аңлатуы буенча анда күрсәтеп үткән көннәр белән идарә итүче тагын 7 йолдыз бар. Алар түбәндәге тәртиптә киләләр:

Кояш - якшәмбе *көн белән идарә итә,*
Ай - дүшәмбе *көн белән,*
Кызыл йолдыз (Марс) - сишәмбе *белән,*
Таң йолдызы (Меркурий) - чәршәмбе *белән,*
Мөштәри (Юпитер) - пәнҗешәмбе *белән,*
Зөһрә йолдызы (Венера) - җомга *белән,*
Зөхәл (Сатурн) - шимбә *белән.*

Кайсы йолдызлар астында йөрегән юлларыгыз?

Бу йолдызлар асылда кешенең тормышы, торышы, гомере белән дә тыгыз элемтәдә торалар, ягъни кеше туган көннән алып гомеренең актык көненә кадәр йолдызлар тәэсирендә яши. Мәсәлән, бала тугач та, кызыл йолдыз тәэсирендә булып, тирә-юньдәге нәрсәләрне өйрәнү омтылышы туа. Шуның өчен дә борынгы заманнардан килгән биләүсәләү гадәте бигрәк тә кызыл йолдыз тәэсиреннән саклау өчен кулланылган. Икенчедән, баланы биләүсәләү, аның тыныч булуына сәбәпче, чөнки биләүсәсез бала ихтыярсыз бик күп хәрәкәтләр ясый, арый. Мондый бала елаучан була. Ата-ана аның нилектән елаганын белми, бала тәненнән юк авыруны эзли. Биләүсәсез бала үсә башлагач та, тиешеннән артык таләпчән була. Йөгәнсез ат шикелле үзенең ата-анасының, якыннарының әледән-әле кәефен боза. Балага бер яшь тулганда ул кояш энергиясен ала. Кояш аңа ихтыярый көч бирә. Бу вакытта инде аны биләүсәләргә ярамый. Ул төс аера һәм матурлыкны белә башлый.

Ике яшьтән Зөһрә йолдызы балага сөйкемлелек китерә, ризыкның да тәмен белә, яхшы белән яманны да аера башлый. Бигрәк тә бу чорда ата-анага үзара тату булу, тормышның ыгы-зыгысын балага сиздермәскә тиеш.

Өч яшьтә балага Таң йолдызы көчле йогынты китерә. Балада белемгә, сәнгатькә, әдәбиятка, тел байлыгына, хезмәткә омтылыш хасил була.

Дүрт-биш яшьтә бала Ай егәрлеген ала. Әлбәттә инде, бу аның үз ихтыярыннан тыш килеп чыга. Бу чорда бала үз өен, үз почмагын таный башлый. Бу вакытта аның үз бүлмәсе булганда, тормышка караш яхшы нәтиҗә бирә.

Биш-алты яшьтә бала Зөхәл йолдызы тәэсирендә кала. Бу чорда ул усаллаша, кireләнә һәм каты күңеллегә, тискәре холыклыга әверелүе дә ихтимал. Мондый вакытта балага дорфалыгы өчен һич кенә дә җәза бирергә ярамый. Аңа бик түземлелек белән җентекләп аңлатырга кирәк. Ул моны бик теләп кабул итәчәк һәм киләчәктә сезгә рәхмәтле булачак.

Алты-җиде яшьтә балалар бик күп нәрсәләрне белеп, аңлый. Бу чорда Мөштәри йолдызының тәэсире көчле. Бу йолдыз дөнья белән килешү, дөньяга үзенең урынын таныту чоры йолдызы. Шушы чорда шәфкатьлелек, юмартлык бөтен гомергә кала торган сыйфат булып камилләшә.

Җиде-сигез яшьтә бала кабат Кызыл йолдыз тәэсиренә кайта һәм шулай һәр җиде-сигез ел саен йолдызлар алышып, космик энергия бирү кабатланып тора. Ниһаять, өлкән яшьтәге кеше организмы космик үзгәрү буласын барометр кебек теге яки бу йолдыздан дулкыннар килә башлау белән тоя башлый. Ә инде организм йолдызлардан артык энергия алса, теге яки бу авыруга каршы тору сәләтен югалта. Андый вакытта һич кичектерми артык энергиядән арыну юлын табарга кирәк. Арыну ысуллары бик күп: кеше белән аралашу, үзеңнең агачыңа сөяләп тору, таш, ут, су аркылы (бу турыда алда тукталырбыз, иншаллаһ).

Җиде яшьтән ундүрт яшькә кадәр бала Таң йолдызы энергиясендә яши. Ул тормышта булган төрле үзгәрешләр белән кызыксына, тиз үзләштерүчән була.

14 яшьтән 22 яшь арасында Зөһрә йолдызының тәэсире аеруча көчле була. Зөһрә йолдыз кешедә тоеп-сизү хисләрен тудыра. Нәфислек, нечкә тойгы, тыйнаклык һәм оялчанлык тойгыларын бирә.

Тоем-сиземләү кешенең аңыннан башка туганлыктан, ир балалар еш кына җенси гөнаһ кылуга да баралар. Шуның белән алар үзләренең киләчәген куркыныч астына куюлары да ихтимал. Әйтик, 14-22 яшьтәге ир бала Зөһрә йолдыздан алган көчле энергия белән, Кызыл йолдыз тәэсирендәге 36-46 яшьтәге хатын-кызга барса, киләчәктә кайтарып ала алмастай җенси салкынлыкка, сәләтсезлеккә дучар була. Бу тискәре тәэсир һичбернинди дәвага да бирешми торган була.

14-22 яшьтәге кыз балалар да еш кына олылардан күрмәкче, буяна башлыйлар. Ләкин бу чорда буяну һич кенә дә аларны яхшылыкка китерми, чөнки Зөһрә йолдызыннан килгән нурларны буяу үзенә алу сәбәпле, кызлар күзе үзенә ала алмый. Асылда аларның сөйкемлелеге чәчәк ата алмый, яшьли югала.

22 яшьтән 36 яшькә кадәр кеше Кояш тәэсирендә булып, үзендә зур ихтыярый көч тудыра һәм организмы ныгый.

36 яшьтән 46 яшькә кадәр кеше Кызыл йолдыз нурлары астында яши. Бу чорда адәм баласы акыллы һәм актив хәрәкәт итә.

46 яшьтән 63кә кадәр кеше Мөштәри йолдызы тәэсирендә яши, тормышта танылa. Бу чор мәртәбә һәм дан чоры.

64 яшьтән 71гә кадәр кеше Зөхәл йолдызы тәэсирендә гомер кичерә. Бу чор эчке фикерләү, фаразлау чоры.

72 яшьтән узгач кеше организмы Уран йолдызы тәэсиренә күчә. Фикер йөртү кыенлаша башлый.

(Дәвамы бар).

Гаяз ибне МӨХӘММӘДХАФИЗ.

Аш-су остасы булыйк!

Кекс

2 стакан катык, 2 стакан он, 1 стакан манный, 1 ст. шикәр, 2 йомырка, 2 аш кашыгы үсемлек мае, 1 чәй кашыгы сода, 10 г тозны туглап, табага салып, мичтә пешерергә (35 минут).

"Минутка"

1 стакан сметана, 2 йомырка, 0,5 стакан шикәр, 2 стакан он, тоз, соданы туглап, табага салып, мичтә пешерергә (30 мин.)

Солы ("Геркулес") печеньесы

Иң элек йомыркага шикәр комы салып, туглагыз. Шуңа эретеп, суытылган маргарин, итарткычтан үткәрелгән "Геркулес" ярмасы һәм он салып, камыр басыгыз.

Аннан соң камырны юка итеп җәегез. Төрле формаларда кискәләгәч, майланган табага тезеп, мичтә пешерегез. Печенье өчен 600 г (4 стакан) "Геркулес", 200 г шикәр комы, 200 г маргарин, 2 йомырка, 200 г он, бер чеметем чәй содасы һәм тоз кирәк.

Котлыйбыз!

Яраткан укытучыбыз Любовь Владимировна Шәйхеләхмәтованың 4нче февральдә туган көне. Без аны шәхси бәйрәме белән котлыйбыз! Тырышып укырга, йөзенә кызыллык китермәскә, дәресләрдә тыныч утырырга сүз бирәбез. Без аңа бәхет телибез.

Тукай районы, Боерган урта мәктәбе, 3 сыйныф укучылары.

Кадерле кызыбыз һәм сеңелебез Гөлназ Нигъмәтҗанованы туган көне белән котлыйбыз! Гөлназ 16нчы мәктәпнең 2нче сыйныфында укый. Гөлназга ныклы сәламәтлек, олы куанычлар, ап-ак кардай ак бәхет, теләкләренең чынга ашуын телибез.

Әнисе, әтисе, апасы Гүзәл.

Апаем Илназ Хәмидуллинны 9нчы февраль - туган көне белән котлыйм. Акыллы, тәүфыйклы, сәламәт, бәхетле булып үсүен телим.

Руслан Зажирский, Тукай районы, Калмаш авылы.

4нче февраль көнне әниебезнең туган көне. Әниебезнең исеме дә матур, гөлләр исеме - Роза. Ул үзе дә дөньядагы иң матур әни. Без аны туган көне белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Алдагы тормышында ныклы сәламәтлек, ак бәхетләр, эшендә зур уңышлар телибез.

Кызлары - Алсу белән Гөлназ. 54нче мәктәп укучылары.

Көмеш кыңгырау

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

Рәссам - **Фаил Ислам**
Язмаларны компьютерда җыючы һәм урнаштыручы
Резидә Кариева

"Көмеш кыңгырау"ны оештыручылар һәм гамәлгә куючылар: халык депутатларының Чаллы шәһәр советы һәм шәһәр хакимияте.

"Көмеш кыңгырау" газетасы Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 466нчы номерлы таныклык белән теркәлде.

БЕЗГӘ КИЛЕГЕЗ, ХАТЛАР ЯЗЫГЫЗ:
423802, Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, 8/7 "Б", 501 бүлмә "Көмеш кыңгырау" газетасы редакциясе.

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
42-01-11 - баш мөхәррир,
42-63-63 - баш хисапчы,
42-26-45 - мәктәпләр һәм хатлар бүлеге.
42-32-49 - компьютерлар бүлмәсе.
42-22-19 - "Серебряный колокольчик" редакциясе.

Редакциягә килгән хатлар рецензияләнми, кире кайтарылмый.

"Көмеш кыңгырау"дан алынган язмаларның чыганагын күрсәтү мәҗбүри.

Яңа ачылган татар балалары газетасына матди ярдәм күрсәтергә теләүчеләр өчен исәп-хисап счеты:
ИНН 1650048918
ГКБ "Автоградбанк" кор/счет 30101810100000000748
расч/счет 40603381051000000014

Газета компьютерда җыелды.
Офсет ысулы белән КП "Яр Чаллы типографиясе"ндә басылды.
Адресы: 1 Май урамы, 6.
Атнага ике тапкыр чыга.
Индекс 31700
Тираж 10406
Басарга кул куелды 4.02.98